КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 25 март г.Казань № 165

2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен раслау турында» 2021 ел, 6 февраль, 60 нчы карары белән расланган 2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын расларга.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына ел саен, 15 гыйнварга кадәр, 2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын үтәү барышы турындагы хисапны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, «Татарстан Республикасының Кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге» коммерциягә карамаган оешмасы катнашында бергәләп, 2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясендә билгеләнгән төп нигезләмәләрне һәм бурычларны тормышка ашыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021ел, 25 март, 165 нче
карары белән расланды

2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасында
кулланучылар кооперациясен үстерү концепциясен гамәлгә ашыру чаралары
планы

| Т/с | Төп бурычлар | Чара исеме | Үтәү срогы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Авыл торак пунктларында яшәүчеләргә күрсәтелә торган, шул исәптән хәзерләү, җитештерү һәм сәүдә эшчәнлеге буенча хезмәтләрнең гомуми күләмен арттыру | Татарстан Республикасының 20 муниципаль районында (Азнакай, Аксубай, Апас, Арча, Баулы, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Алабуга, Зеленодольск, Кайбыч, Лаеш, Лениногорск, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Питрәч, Сарман, Спас) кулланучылар кооперациясе оешмалары эшчәнлегенең барлык төрләрен яңарту | 2021 ел | «Татарстан Республикасының Кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге» коммерциягә карамаган оешмасы (алга таба – Татарстан кулланучылар берлеге) |
| | | Татарстан Республикасының 43 муниципаль районында халыкка комплексلы хезмәт күрсәтүнең блоклы-модульле пунктларын төзүне дәвам итү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – ТР АХһАТМ), Татарстан |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Кулланучылар кооперациясе оешмаларының авыл хуҗалыгы продукциясен һәм көндәлек кулланыштагы азык-төлек товарларын сату ярминкәләрендә, шулай ук Татарстан Республикасында һәм аннан читтә оештырыла торган башка ярминкә һәм күргәзмә чараларында катнашуы | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Саба, Әлмәт, Кама Тамагы, Тәтеш, Балык Бистәсе муниципаль районнарында җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтүче Татарстан Республикасы кулланучылар кооперациясе оешмалары тарафыннан төрле категорияләрдәге халыкның сатып алуга карата ихтыяҗы нигезендә кулинария продукциясе, камыр татлы һәм күмәч әйберләре җитештерү һәм сату күләмнәрен арттыру | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүче Татарстан Республикасы кулланучылар кооперациясе оешмаларының Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү һәм гомуми белем бирү оешмаларында җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтү буенча конкурсларда катнашуы | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Авыл торак пунктларында гражданнарга, шулай ук ваклап сату предприятиеләрендә заказчы йортында хезмәтләр күрсәтүгә заказлар алу аша күчмә көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | (Баулы, Лениногорск, Ютазы муниципаль районнарында катлаулы көнкүреш техникасын ремонтлау, утын белән тәэмин итү, Сарман муниципаль районында коеларны, Азнакай, Тәтеш, Балык Бистәсе муниципаль районна-рында тегермәннәрне чистарту) | | |
| | | 30 җәмәгать туклануы предприятиенең еллык товар әйләнешен кимендә 10 процентка арттыруны тәэмин итү һәм аларның гомуми товар әйләнеше күләмен 800 млн.сумга кадәр җиткерү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Татарстан Республикасының 40 муниципаль районында сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы кулланучылар кооперациясе оешмалары тарафыннан сатулар рентабельлеге күрсәткечен 2 проценттан түбән булмаган күләмдә, шул исәптән чыгымнарны кыскарту хисабына тәэмин итү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Язгы кыр һәм урып-җыю эшләрен үткәрү чорында Татарстан Республикасының 43 муни-ципаль районында (дача ширкәтләрен дә кертеп) ел саен халыкка сәүдә хезмәте күрсәтүне оештыру | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| 2. | Кабул итү-хәзерләү пункт-лары челтәрен арттыру һәм авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чимал хәзерләү һәм эшкәртү күләмнәрен арттыру | Татарстан Республикасының 43 муниципаль рай-онында кулланучылар кооперациясе оешмалары тарафыннан еллык хәзерләү әйләнешен кимендә 10 процентка арттыруны тәэмин итү һәм 2025 елда аларның гомуми хәзерләү әйләнеше күләмен 14,4 млрд.сумга җиткерү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасының 13 муниципаль районында (Аксубай, Әлки, Апас, Арча, Югары Ослан, Чүпрәле, Алабуга, Зеленодольск, Менделеевск, Яңа Чишмә, Питрәч, Спас, Теләче) район кулланучылар кооперациясе оешмалары составында хәзерләү оешмасын төзү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Бер ишегалдыннан авыл хуҗалыгы продукциясен һәм чимал сатып алулар күләмен 2020 елда 29 мең сумнан 2025 елда 35 мең сумга кадәр арттыру | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Хәзерләү оешмалары тарафыннан ит, йон һәм күн чималы сатып алу, эшкәртү һәм реализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләрне үзләштерү | 2021 – 2025 еллар | ТР АХһАТМ, Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Татарстан Республикасында агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру кысаларында авыл хуҗалыгы продукциясен хәзерләү һәм саклау буенча матди-техник базаны яңарту | 2021 – 2025 еллар | ТР АХһАТМ, Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Татарстан Республикасының 43 муниципаль районында икътисадый актив, эше булмаган халыкны, шул исәптән каникуллар чорында урта һәм югары уку йортлары укучыларын, пенсионерларны һәм вакытлыча эшләмәүчеләрне кыргый җимешләр, җиләкләр һәм гөмбәләр, дару-техник чимал җыю эшчәнлегенә җәлеп итү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| 3. | Үз продукциясен һәм чималын җитештерү һәм | Кулланучылар кооперациясенең 37 җитештерү оешмасында ел саен җитештерү үсешен кимендә | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | реализацияләү күләмнәрен арттыру | 10 процент дәрәҗәсендә тәэмин итү һәм аларның гомуми күләмен 2025 елда 3 млрд.сумга җиткерү | | |
| | | Кулланучылар кооперациясе оешмаларының җитештерү объектларын модернизацияләүне дәвам итү, шул исәптән икмәк пешерү йортларының технологик җиһазларын, ит эшкәртү, татлы ашамлыклар һәм макарон әйберләре җитештерү, алкогольсез продукцияне агызып салу, балыклар эшкәртү, яшелчәләр тозлау һәм консервацияләү, шулай ук кыргый җимешләр, җиләкләр һәм гөмбәләр, дару-техник чималны эшкәртү цехларын алмаштыру | 2021 – 2025 еллар | ТР АХһАТМ, Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | 32 кулланучылар кооперациясе оешмасында азык-төлек продукциясе (икмәк-күмәч әйберләре һәм татлы ашамлыклар) җитештерү буенча Hazard Analysis Critical Control Points дигән сыйфат системасын кулланышка кертү һәм Алексеевск, Баулы, Бөгелмә, Зәй һәм Кайбыч муниципаль районнарының биш кулланучылар кооперациясе оешмасында аның эшләвен тәэмин итү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| 4. | Җитештерү егәрлекләренең максималь йөкләнешен тәэмин итү | Энергия саклау технологияләрен кулланып, кулланучылар кооперациясе оешмаларын (шул исәптән икмәк-күмәч әйберләре, татлы ашамлыклар, казылык эшләнмәләре җитештерү өлкәсендә) реконструкцияләүне дәвам итү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Хәзерләнгән авыл хуҗалыгы чималын, терлекчелек продукциясен эшкәртү һәм үз | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | продукциясен җитештерү буенча җитештерү цехлары һәм участоклары йөкләнешен 80 процентка тәэмин итү | | |
| 5. | Авыл торак пунктларында яшәүчеләргә күрсәтелә торган ваклап сатудагы товар әйләнеше, көнкүреш хезмәтләре күләмнәрен арттыру | Кулланучылар кооперациясе оешмасының ваклап сатудагы товарлар әйләнешенең еллык үсешен кимендә 5 процент дәрәҗәсендә тәэмин итү һәм ваклап сатудагы товарлар әйләнешенең гомуми күләмен 2025 елда 6,4 млрд.сумга кадәр җиткерү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Татарстан Республикасының кулланучылар кооперациясе оешмаларына Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан ерак урнашкан авыл торак пунктларына беренчел кирәкле товарлар илтү буенча ягулык-майлау материаллары чыгымнарының бер өлешен каплауны тәэмин итү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Кулланучылар кооперациясе оешмаларының сөт һәм сөт продукциясен мәҗбүри маркировкалауны этаплап гамәлгә кертү системасында катнашуын тәэмин итү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Идентификацияләү чаралары белән мәҗбүри маркировкаланырга тиешле аерым товарлар исемлеген раслау турында»<br>2018 елның 28 апрелендәге б-792 номерлы боерыгын үтәү (2021 елның 1 июненнән «туңдырма» һәм «сырлар» категорияләре өчен) | | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | 895 авыл торак пунктында беренчел кирәкле товарлар, шул исәптән үз җитештерүдәге продукция һәм Татарстан Республикасында җитештерелгән товарлар белән күчмә сәүдә оештыру | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Татарстан Республикасының авыл торак пунктларына беренчел кирәкле товарлар илткәндә һәр автолавканың ваклап сатудагы товар әйләнешенең айлык күләмен кимендә 250 мең сумда, шулай ук логистика чыгымнарын киметү хисабына эшләп торучы автолавкаларны файдалану нәтиҗәлелеген тәэмин итү | 2021 – 2025 еллар | ТР АХһАТМ, Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Татарстан Республикасының 16 муниципаль районында (Әгерже, Азнакай, Актаныш, Алексеевск, Әлмәт, Балтач, Буа, Биектау, Кама Тамагы, Кукмара, Мамадыш, Менделеевск, Балык Бистәсе, Саба, Тәтеш, Чирмешән) ябык булган 110 авыл кибетне Татарстан Республикасы кулланучылар кооперациясе оешмаларының үз акчасы исәбенә яңадан эшләтә башлау (шул исәптән 2021 елда – 40, 2022 елда – 70) | 2021 – 2022 | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Беренчел кирәкле товарларны сатуны гамәлгә ашыру өчен арендага бирелгән кибетләрне файдалану (Әлмәт, Мамадыш, Саба, Баулы, Бөгелмә, Зәй район кулланучылар җәмгыять-ләре) | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Электрон коммерцияне үстерү (e-commerce дөньякүләм лидер интернет кибетләр (шул исәптән Ozon, Wildberries интернет-кибетләре аша) Татарстан Республикасы кулланучылар кооперациясе оешмалары продукциясен сатуларда катнашу), шулай ук кулланучылар кооперациясе оешмаларында бердәм фирма бренды астында җитештерелә торган товарларны сату өчен маркетплейслар (агрегаторлар) белән үзара бәйләнешне тәэмин итү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| 6. | Кулланучылар кооперациясе оешмалары хезмәткәрләренең эшлекле активлыгын арттыру | Татарстан кулланучылар берлегенең идарә һәм контроль органнары (Совет, Идарә, ревизия комиссиясе) эшчәнлегендә пайчыларның максималь катнашуын тәэмин итү | 2021 – 2025 еллар | ТР АХһАТМ, Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Татарстан Республикасының кулланучылар кооперациясе оешмаларына пайчылар җәлеп итү һәм аларның санын 36 мең кешегә кадәр җиткерү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Татарстан Республикасында кооператив хәрәкәтен массакүләм мәгълүмат чараларында (шул исәптән телевидениедә, https://tps.tatarstan.ru, https://agro.tatarstan.ru) яктырту аша популярлаштыру | 2021 ел | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Пайчыларны электрон исәпкә алу системасын кулланышка кертү һәм пай кенәгәләрен бирү эшләрен төгәлләү | 2021 ел | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| 7. | Кулланучылар кооперациясе оешмаларын мәгълүмати | Кулланучылар кооперациясе оешмаларын (маркетинг, юридик, финанс яктан озата бару, семинарлар, конференцияләр үткәрү) тизләтеп | 2022 ел | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | тәэмин итү системасын булдыру | үстерүгә булышлык итә торган мәгълүмати-консультация хезмәтләре күрсәтү үзәген булдыру | | |
| | | Татарстан Республикасының кулланучылар кооперациясе оешмаларының zakazrf.ru һәм bp.zakazrf.ru сәүдә мәйданчыкларында актив катнашуын тәэмин итү | 2021 ел | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Кулланучылар кооперациясе оешмалары тарафыннан Татарстан кулланучылар берлегенең https://tps.tatarstan.ru/produktsiya.htm рәсми сайтында һәм Республика маркетинг үзәгенең http://rmcrt.ru/goods.html рәсми сайтында чыгарыла торган продукция (икмәк-күмәч, макарон әйберләре, казылык эшләнмәләре, татлы ашамлыклар) реестрын яңарту, аларда катнашучылар санын 18 кулланучылар кооперациясе оешмасыннан 40 кулланучылар кооперациясе оешмасына кадәр җиткерү | 2021 ел | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| 8. | Кулланучылар кооперациясе оешмаларын цифрлаштыру | Кулланучылар кооперациясенең 400 кибетендә товарлар килүне, саклауны һәм сатуны исәпкә алуны автоматлаштыруны тәэмин итү һәм «зур мәгълүматлар» белән эшләүнең электрон системасына күчү (товар-матди кыйммәтләрне исәпкә алу) | 2021 ел | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте белән берлектә, «Кооператив онлайн» уртак цифрлы продуктны үзләштерүне тәэмин итү (пайчыларның электрон исәбе) | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Пайчылар белән исәп-хисапларның бердәм системасын (кооператив кассасы) электрон рәвештә кертү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Кулланучылар кооперациясе оешмалары эшчәнлегенең барлык төрләрендә, Blockchain мәгълүматларын саклау ысулын кулланып, цифрлаштыруны гамәлгә кертү (сәүдә процессларын автоматлаштыру, товарларны өйгә китереп бирү буенча цифрлы сервислар, шул исәптән мобиль кушымта эшләү) | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| 9. | Кулланучылар кооперациясе оешмаларының финанс тотрыклылыгын арттыру | Түләүгә сәләтлелек, активлар ликвидлылыгы, әйләнеше, үз акча белән тәэмин ителеш, эшчәнлек рентабельлеге коэффициентларын арттыруны тәэмин итү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Түләү дисциплинасының үтәлешен тәэмин итү, шул исәптән Татарстан Республикасының кулланучылар кооперациясе оешмалары тарафыннан салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәләрне үтәү, шулай ук кирәк булганда шикле бурычлар буенча резерв булдыру, үз акчаны арттыру | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Татарстан Республикасында билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән түбән булмаган күләмдә эш хакын үз вакытында түләүне тәэмин итү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 10. | Кулланучылар кооперациясе оешмалары хезмәткәрләренең кадрлар потенциалын һәм һөнәри белем дәрәҗәсен арттыру | Татарстан кулланучылар берлеге тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк берлегенең югары белем бирүче «Россия кооперация университеты» коммерциягә карамаган автоном белем бирү оешмасының Казан кооперация институтында (филиалда) (алга таба – Кооперация институты) ел саен югары белем алу өчен түбәндәге белгечлекләр буенча 25әр белгеч әзерләүгә заказ формалаштыру: «Товарлар гыйлеме һәм кулланучылар товарлары сыйфатын экспертизалау», «Иҗтимагый туклану продукциясе технологиясе һәм кулланучылар товарлары сыйфатын экспертизалау», «Икмәк, татлы ашамлыклар һәм макарон әйберләре технологиясе», «Икътисад һәм тармаклар буенча бухгалтерлык исәбе» һәм «Продуктлар һәм чимал әзерләүче» | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча), Кооперация институты |
| | | Югары белем бирүче мәгариф оешмаларын һәм һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаганнан соң кулланучылар кооперациясе оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә ярдәм күрсәтүне тәэмин итү (бер мәртәбә һәм айлык түләүләр бирү) | 2021 – 2025 еллар | ТР АХҺАТМ, Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |
| | | Икмәк пешерүчеләрнең һөнәри осталык буенча республика һәм бөтенроссия конкурсларында, шулай ук «Россия икмәк пешерүчеләр һәм кондитерлар гильдиясе» коммерциягә карамаган партнерлыгы һәм Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләренең үзәк берлеге | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | тарафыннан оештырыла торган «Икмәк, син – дөнья» икмәк пешерү буенча бөтендөнья форумында актив катнашу | | |
| | | Кооперация институты белән берлектә, белгечләрне яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясн күтәрү (яңа технологияләрне үзләштерү һәм продукция җитештерү курслары, тренинглар, һөнәри осталык конкурслары, мастер-класслар, форумнар, түгәрәк өстәлләр) буенча комплекслы чаралар үткәрү | 2021 – 2025 еллар | Татарстан кулланучылар берлеге (килешү буенча), Кооперация институты |